Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

13 ноябрь, 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татар Тау Иле авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыеннарын билгеләргә:

1.1. Татар Тау Иле авылында. Халык җыенын өч этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 29 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Совет урамы, 16а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Белкино, Яңа, Төзүчеләр, Таулы урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2019 елның 3 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Совет урамы, 16а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Комсомол, Совет урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2019 елның 6 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Совет урамы, 16а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Пионер, Чапаев урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Татар Тау Иле авыл җирлеге Татар Тау Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Княжа авылында. Халык җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 4 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Химиклар урамы, 3 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Химиклар урамы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 5 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 21А йорты янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Үзәк, Яшел, Мальковка урамнары йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Татар Тау Иле авыл җирлеге Княжа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

Рус Тау Иле авылы зиратын коймалау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татар Тау Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Шаров